Республика Татарстан **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**	**Татарстан Республикасы** **САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘЛМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2017 ел,2 ноябрь № 5

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлегенең социаль инфраструктурасының
2017 елдан 2026 елга кадәрге чорга
комплекслы үсеш программасын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 1 октябрендәге 1050 номерлы «җирлекләрнең, шәһәр округларының социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларына таләпләрне раслау турында» карары, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Генераль планы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең социаль инфраструктурасының 2017 елдан 2026 елга кадәрге чорга комплекслы үсеш программасын расларга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсмипорталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru махсус мәгълүмат стендларында һәм Сарман муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Әлмәт авыл җирлеге
Башкарма комитеты житәкчесе Д. Ә. Газизов